Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Яңа Никольский авыл җирлегенең
Завод торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы
КАРАРЫ

25 ноябрь 2020 ел №2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, 2020 елның 21 ноябрендә 14 сәгать 00 минутта, узган гражданнарның этаплы җыен нәтиҗәләре нигезендә түбәндәге: “Сез 2021 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Никольский авыл җирлеге Завод авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 2000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрүгә юнәлдерү белән килешәсезме: кышкы һәм җәйге чорда юлларны карап тоту?” соравы буенча гражданнар җыены беркетмәсе тәзелде

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 32 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 18 кеше, бу 56 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

гражданнар җыенында катнашучыларның 18 «РИЗА» позициясе өчен тавыш бирде; гражданнар җыенында катнашучыларның 0 «КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Никольский авыл җирлегенең Завод торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - чынбарлыкка туры килә.

2.Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Никольский авыл җирлегенең Завод авылында яшәү урыны буенча теркәлгән, даими яшәүче булган һәр балигъ булган кешедән үзара салым средстволарын 2021 елда 2000 сум күләмендә кертергә.

3. Җыелган үзара салым средстволарын җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә: кышкы һәм җәйге чорда юлларны карап тоту.

4. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетысында бастырырга, Яңа Никольский авылы, Үзәк урам, 100 нче йорт; Салкын Алан авылы, Луговая урамы, 60 нчы йорт; Иштирәк авылы, Чишмә урамы, 3 нче йорт; Хазовка, Болтаево, Завод, Кәминкә, Кече Шуган, Поташная Поляна, Сосновка бистәләре территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU), Әлмәт муниципаль районы сайты «Интернет» челтәрендә урнаштырырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче Г.А. Кәримова